ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.04.2020 г. Заинск № 146

**«2019-2023 елларга Зәй муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 28 мартындагы 165 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. «2019-2023 елларга Зәй муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 28 мартындагы 165 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортының «Программаның максаты һәм бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаның максаты һәм бурычлары | Программаның максаты:<br>Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында кече һәм урта, социаль эшмәкәрлекне үстерү өчен уңайлы икътисадый, хокукый һәм оештыру шартлары һәм инструментлары булдыру.<br>Программаның бурычлары:<br>1. Уңайлы мохит тудыру һәм эшмәкәрлекне, шул исәптән социаль эшмәкәрлекне үстерү өчен административ каршылыкларны киметү;<br>2. Эшмәкәрнең уңай образын булдыру, бизнес алып баруга сәләтле кешеләрне ачыклау;<br>3. Үзмәшгульләр өчен яңа салым режимын популярлаштыру; |

| | |
|---|---|
| | 4. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының халыкара базарларга чыгуына ярдәм итү;<br>5. Кече бизнесның инновацион инфраструктурасын үстерүгә ярдәм итү;<br>6. Эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм; |

1.2. 3 бүлектә:

а) 3.1 бүлекчәдә 1 абзацта «региональ» сүзләрен «территориаль» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «шул исәптән социаль эшмәкәрлек» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 3.9 бүлекчәсен өстәргә:

«3.9 Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына (алга таба - КУЭС) мөлкәти ярдәм күрсәтү. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү урта һәм кече бизнесны үстерү буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе санала.

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 209 номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, Зәй муниципаль районында 5 күчемсез мөлкәт объекты кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка арендага бирү өчен, шул исәптән ташламалы шартларда, муниципаль милек исемлегенә кертелгән.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына (КУЭС) мөлкәти ярдәм күрсәтү муниципаль милекне хуҗалык әйләнешенә җәлеп итүгә, кече һәм урта бизнесның милек базасын ныгытуга ярдәм итәчәк һәм шул ук вакытта аренда түләүләре керү, шулай ук арендаторлар тарафыннан милекне сатып алу хисабына бюджетның табышлылыгын арттырачак.

«Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арасында җитештерү һәм административ биналар, торак булмаган биналар, җир кишәрлекләре, транспорт чаралары, җиһазлар кебек мөлкәти ярдәм төрләренә ихтыяҗ зур.

2019 елда 923,0 квадрат метр күчемсез милек арендага бирелде, шуның 525,4 квадрат метры - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, бу арендага бирелгән милекнең гомуми мәйданының 57% ын тәшкил итә. Муниципаль милекне арендалаган өчен түләүләр билгеләнгән срокларда керә.

Зәй муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү түбәндәге принципларда төзелә:

- мәгълүмат ачыклыгы: Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru/ Зәй муниципаль районы муниципаль мөлкәте реестрына кертелгән мөлкәт турында, исемлеккә кертелгән мөлкәт турында, мөлкәти ярдәм күрсәтүне җайга сала торган хокукый актлар, мондый актларның проектлары турында, КУЭС өчен милек буенча эшне алга этәрүдә реклама һәм мәгълүмат кампанияләре уздыру турында мәгълүмат урнаштыру;

- КУЭСның мөлкәти ярдәм алуга тигез керүе: кече һәм урта эшмәкәрлек субектларына милек итеп һәм (яки) файдалануга бирү турында карарларны әзерләү, кабул итү һәм үтәү процессында көндәшлекне яклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәү;

- муниципаль милеккә кергән, яңа ачыкланган, шулай ук файдаланылмый торган, нәтиҗәсез файдаланыла торган яисә билгеләнмәгән мөлкәт исемлегенә кертүнең өстенлеге, мондый мөлкәттән файдалану җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җирле үзидарә органнарын урнаштыру өчен кирәк булган очраклардан тыш.

- арендалана торган дәүләт һәм муниципаль милекне сатып алуга КУЭСның өстенлекле хокукы гамәлгә ашырылган мөлкәтне алыштыру максатында исемлекне ел саен яңа объектлар белән тулыландыру;

- исемлеккә кертелгән мөлкәткә ихтыяҗ: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка арендага бирелә алмый яки алар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла алмый торган милек исемлегенә кертелмәү.

Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru/ (кече бизнес икътисады вкладкасы) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 2020 елның 2 кварталында «КУЭСка мөлкәти ярдәм» юнәлеше буенча бүлек булдырылачак. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага милек бирү буенча вәкаләтле органнарның эшчәнлеге административ регламент белән җайга салынган.

Муниципаль программа кысаларында ел саен Зәй муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль милке исемлегендәге мөлкәт объектлары санын кимендә 10%ка арттыру, КУЭСка арендага тапшырылган объектларны елына 2 объекттан да ким булмаган күләмдә арттыру, шулай ук ел саен үткәрелә торган аукционда катнашучылар санын 10%ка арттыру планлаштырыла.

1.3. «2019-2023 елларга Зәй муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру буенча төп чаралар исемлегенә, 11 пункттан соң, 12 һәм 13 пунктларны һәм түбәндәге чараларны өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 12.КУЭСка мөлкәти ярдәме | 12.1. Зәй муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль милке исемлегендә объектлар санын ел саен 10% тан да ким булмаган күләмдә арттыру(%)<br><br>12.2. Арендага тапшырылган КУЭС объектларын арттыру (бер.)<br><br>12.3. Мөлкәт сатып алуга аукционнарда катнашучылар санын арттыру (ел саен 10% ка арттыру) | Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы | 2020-2023 еллар | - | 2020е.-10%<br>2021е.-10%<br>2022е.-10%<br>2023е.-10%<br><br>2020е.-2<br>2021е.-2<br>2022е.-2<br>2020е.-2<br><br>2020е.-10%<br>2021е.-10%<br>2022е.-10%<br>2023е.-10% |
| 13. КУЭС, шул исәптән социаль эшмәкәрләргә ярдәм | 13.1. КУЭС һәм КУЭС сыйфатында теркәлергә планлаштырган физик затлар өчен социаль эшмәкәрлек буенча уку-укыту семинарлары уздыру<br><br>13.2. КУЭС, шул исәптән | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге,<br><br>Татарстан Республикасы | 2020-2023 еллар | - | 2020е.-1<br>2021е.-1<br>2022е.-1<br>2023е.-1 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | социаль эшмәкәрләргә, әзерлек, яңадан әзерләү һәм хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү өлкәсендә ярдәм . | эшмәкәрлекне яклау үзәге (килешү буенча) | | | 2020е.- 2дән ким түгел<br>2021е.- 2дән ким түгел<br>2022е.- 2дән ким түгел<br>2023е.- 2дән ким түгел |

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

3. Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары М.И. Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

А.Н. Симашева
3 41 33